| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Петровско-Заводского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Петровский Завод<br>авыл җирлеге Советы |

РЕШЕНИЕ

КАРАР

21 сентябрь 2020 ел

№7

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бер кеше кулындагы башкарма орган буларак коммерциягә карамаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай нигездә катнашуга яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) бер кеше кулындагы башкарма орган буларак яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 15 августындагы 10 номерлы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советы карарын гамәлдән чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлешенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советы карар бирде:

Гамәлдән чыгарырга:

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 15 августындагы 10 номерлы Петровский Завод авыл җирлеге Советы карарын.

«Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 15 августындагы 10 номерлы Петровский Завод авыл җирлеге Советы карарына яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәте турында» Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советы карарын.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы

Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе: А.Б. Хөснетдинов